Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районының «Акбуре авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Акбуре авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАРЫ

2019 елның 9 нчы декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Акбуре авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 октябрендәге 61-122 номерлы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, 2019 елның 17 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Акбуре авыл җирлегендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде: "2020 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Акбуре авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлардан , Бөек Ватан сугышында катнашучылар , 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалидлардан кала) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерелү белән килешәсезме:

- Комсомол урамында вак таш җәю (вак ташны сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләргә түләү);
- юлларны кардан чистарту;
- су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

«РИЗА" "КАРШЫ" "ТЫЕЛУЧЫЛАР".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 363 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 253 граждан кертелгән.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза» позициясе өчен 253 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбуре авыл җирлеге Акбуре авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьлә буенча кабул ителгән карарны танырга: «2020 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Акбуре авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлардан , Бөек Ватан сугышында катнашучылар , 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалидлардан кала) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерелү белән килешәсезме:

- Комсомол урамында вак таш җәю (вак ташны сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләргә түләү);
- юлларны кардан чистарту;
- су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3. Әлеге карарны Акбуре авыл җирлегенең мәгълүмати стендлары аша халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

ТР Яңа Чишмә муниципаль районы
Акбуре авыл җирлеге Башлыгы Җ. М.Җәләлетдинов